**ТАТАРСТАН Республикасы**
**Аксубай**
**муниципальрайоны**
**муниципаль беремлеге**
**ИСКЕ ИЛДЕРЕК АВЫЛЫ**

**Республика ТАТАРСТАН**
**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**село Старое Ильдеряково**

**Совет Староильдеряковского сельского поселения**

**Сч. №40204810000000230012 к\сч.30101810000000000805 ИНН-1603000718 БИК 049205805 КПП-160301001 ОКПО- 94318576 ОАО «Ак Барс» Банк р.п.Аксубаево ЛБ 039140011 Ст Ил СП**
**Тел.: 4-47-30**

---

**КАРАР**

№ 33 11.10.2021 ел

**Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кабул итү хакында» 18.02.2019 ел, №95 карарына (02.02.2020 ел, № 124, 16.12.2020 ел, № 13 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.04.2021 ел, № 116-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кабул итү хакында» 18.02.2019 ел, №95 карарына (02.02.2020 ел, № 124, 16.12.2020 ел, № 13 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**- 14 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«чит ил гражданлыгы (подданныйлык) алу йә яшәүгә рөхсәт алу яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ, бу хакта муниципаль хезмәткәргә билгеле булган көнне, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданныйлык) алган йә яшәүгә рөхсәт алу яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, гражданлык алу турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә»;

**- 14 бүлекнең 1 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданының муниципаль хезмәттә булырга хокукы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданныйлыгы) туктатылу турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданының муниципаль хезмәттә булырга хокукы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданныйлыгы) туктатылган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә язма рәвештә хәбәр итәргә.»

- **15 бүлекнең 1 пунктындагы 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«7) әгәр дә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, чит ил гражданлыгы (подданныйлыгы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу.»
- **24 бүлегендәге 1 пунктның 2 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.**
- **5 бүлегендәге 1 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату».
2. Әлеге карарны Иске Илтерәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе С.М. Маклаков